КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 15 сентябрь г.Казань № 1136

2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының төп параметрлары турында, 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразы, 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проекты хакында

2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының төп параметрлары турындагы, 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразы, 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проекты хакындагы докладларны тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының төп параметрларын хупларга.

2. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразын, 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проектын исәпкә алырга.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына 2023 елның 5 октябренә кадәр «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектын, әлеге закон проекты белән бер үк вакытта

тапшырыла торган документларны һәм материалларны теркәп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә карауга кертергә.

4. Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына 2023 елның 5 октябренә кадәр «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә карауга кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин